Нәсыйхәт

Җомга 17 гыйнвар 2014 №25

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы

# Бишектән ләхеткәчә гыйлем ал!

## Гыйнвар аенда ун көн дәвамында төрле авыллардан килгән 30 имам мәдрәсәдә гыйлемнәрен арттырдылар. Мондый юнәлештә мәдрәсә әле беренче адымнарын гына ясый.



Мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт авыл имамнарына дәрес бирә. Фәнис Миннеханов фотосы

**Киләчәктә кичке бүлек шәкертләренең саны артканнан артыр дип фаразларга була. Чөнки бирегә килгән укучылар әлеге укыту ысулын хупладылар һәм авылдагы башка кешеләрне дә мәдрәсәгә укырга килергә өндәрбез дип сүз куештылар. Имамнарның бирегә җыелып гыйлем алулары иң элек бердәмлек рухын ныгытуга уңай йогынты ясады. Алар бер сафта басып намазлар укыдылар, бер өстәл артына утырып чәйләр эчтеләр, фикер алыштылар.**

Аларга белем бирергә шәһәребезнең иң тәҗрибәле имамнары җәлеп ителде. Алар үзләренең тормыш тәҗрибәләреннән чыгып, имамнарга вәгазьләр сөйләделәр, киңәшләрен әйттеләр. Мәдрәсә укытучыларының да әлеге укуны оештыруга керткән өлешләре зур булды. Бирегә килгән өлкән имамнарга гыйлем бирү махсус методика һәм аерата зур тырышлык таләп итсә дә, мөгаллимнәрнең чыгышлары укучыларның күңеленә сеңәрлек итеп оештырылган иде. Алар имам вазыйфаларының бик җаваплы икәнлеген аңлатырга тырыштылар, һәм бүгенге вәзгыятьтә имам кеше зур шәргый һәм дөньяви белемгә ия булырга тиешлеге турында сөйләделәр. Укытуда Коръән, фикх, тәфсир, гарәп теле, хәдис, сира, гакыйдә, әхлак, Пәйгамбәрләр тарихы фәннәренә аерата игътибар ителде. Укуның мөселман әхлак нормаларына туры килүче таләпчән кагыйдәләргә нигезләнүе һәм укыр өчен барлык шартлар да тудырылган булуы укучыларны бирегә җәлеп итеп торды. Аларга ял итү һәм яхшы туклану өчен барлык шартлар да тудырылуы, кунып укырга теләүчеләрнең торак белән тәэмин ителүе уку процессының нәтиҗәле булуында шик калдырмады.

Һәркем мәдрәсәгә килеп укый ала. Бер көнлек гомеребезне фани дөнья өчен генә, мал җыеп кына үткәрмик. Без, мөселманнар, үз динебезнең таралуын, аның нуры бөтен тарафны яктыртып торуын һәм бу дингә ияргән халыкларның бәхетле булуларын телибез. Әмма, әгәр без үзебез шушы ислам диненең нигезләрен яхшы белмәсәк, аны кирәкле дәрәҗәдә ихтирам итмәсәк һәм аның васыятьләрен тотмасак, безнең бу өметләребез коры хыял гына булып калачак. Динне хөрмәтләү исә аны өйрәнү һәм шуның белән гамәл кылудан гыйбарәт. Шулай булмаганда, дин туфрак астында күмелеп торучы алтын кебек яшерелеп торыр. Гыйлем – Исламның нигезедер. Бу дөньяда иң зур байлык-ул иман байлыгы! Шуны онытмыйча, һәр ике дөнья бәхетенә лаеклы булып яшәсәк иде.

**ФӘНИС хәзрәт (Яшел Тау авылы имамы):**
- Пәйгамбәребез бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем алырга кушкан. Интернетлы, дини китаплар күп итеп басылган бу заманда хикмәткә һәм белемгә ия булган имам гына тулы канлы итеп эшен алып бара ала, үзеннән соң кешеләр ияртергә сәләтле. Шуңа күрә барлык кешеләрне дә гыйлем алырга чакырам.

**ГАЗИНУР хәзрәт (Ямаш авылы имамы):**
- Шуны әйтергә кирәк, монда килгәнче без күп әйберне белмәгәнбез икән. Монда алган дини белем безнең күбебезнең дөньяга, тирә-юньгә, табигатькә карашын, яшәү рәвешен дә үзгәртте дисәм ялгыш булмас.

**ИЛСУР хәзрәт (Кыерлы авылы имамы):**
-Әлеге гыйлем алу мәҗлесләрендә катнашуыма мин бик шат. Мәдрәсәдәге мохит, уку өчен бөтен уңайлыклар булуы бездә уку теләген тагын да арттырды. Оештыручыларга, көнен көненә ялгап безгә ашау әзерләгән пешекчеләргә, укыткан мөгаллимнәргә олы рәхмәтемне җиткерәсем килә. Аларга Аллаһ Раббыбыз хәерле саулык-сәламәтлек, эшләрендә уңышлар насыйп итсен.

# Аллаһ барысын да белеп тора

## Әлхәмдүлилләһи раббил галәмин! Хак дин - исламга юл ачкан өчен бер Аллаһыга рәхмәтлемен!

Үзебезнең Мамадыш мәдрәсәсендә укуым миңа күп нәрсәгә җавап табарга ярдәм бирде. Дин турында күп сөйлибез, ләкин нәрсә соң ул дин? Дин - ул адәм баласының дөньяга карашы, тапкан юлы. Һәр татар телендә сөйләшкән кеше үзен мөселман дип хис итә, ләкин Аллаһы Тәгаләне бер, бар һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәд салләлаһу галәйһи вә сәлләм дип белү генә җитми икән әле. Үзеңнең яшәү рәвешеңне дә тикшереп карарга кирәк. Һәр яңа көнне каршылагач, үз-үзеңә: “Мин туры юлда йөримме, Аллаһы Тәгаләнең кушканын үтимме, тыйганыннан тыеламмы? – дигән сорауны куярга кирәк икән. Дөньяда без нәрсә өчен яшәргә тиеш? Мәдрәсәдә уку дәверендә, мин яшәүнең мәгънәсе озак яшәүдә түгел, ә ничә яшьтә дөньядан үтсәң дә, кылган игелекләрең, эшләгән явызлыкларыңнан күп булырга тиеш икәнлегенә төшендем. Тормыш ул - озын юл. Бу юлны күп сынаулар аша үтәргә туры килә. Юлның башы бишек булса, ахыры - кабер. Кыямәт көнендә без тормышны нинди гамәлләр кылып үткәргән булсак, шулар нигезендә Аллаһы Тәгалә алдында имтихан тотачакбыз икән. Безнең остазларыбыз ислам диненең нечкәлекләрен аңлатырга, безнең баш эченә кереп урнашкан каты бозны кузгатырга, эретергә күп тырышлык куялар. Мәдрәсәбезнең ишеге һәркемгә ачык, күңелләрегездән “белмим”, “ булдыра алмыйм” – дигән уйны чыгарып ташлагыз. “Авырыйм, хәтерем начар, миннән булмый” ,– димәгез. Авыруга дәваны күрәзәчеләргә, сихерчеләргә барып эзләмәгез. Мәчетләрегезгә килегез. Аллаһ Тәгаләнең пәйгамбәребез с.г.в. гә Җәбраил фәрештә тарафыннан ирештерелгән Коръәнендә дәва да бар. Мәчетләрдә тәнеңә дә, җаныңа да шифа табасың. Дин мәсьәләсендә үзеңне борчыган сорауларга җавапны да алырсың. Пәйгамбәребез с.г.в. нең бер хәдисендә “Сез гамәл кылыгыз, чөнки һәр кеше нәрсә өчен яратылган булса, аңа шул җиңеләйтелә, ” – ди.

Дөнья һәм ахирәт гамәлендә кимчелек кылырга ярамый дигәнне аңлата ул. Тагын бер хәдистә “Галим яки гыйлем өйрәнүче, яки тыңлаучы, яки гыйлемне сөюче бул! Ләкин бишенчесе булма, һәлак булырсың”, – диелә. Ягъни гыйлемне дошман күрүче булмаска кирәк, чөнки һәлакәт шунда.

Йомгаклау сүзе итеп шуны әйтәсем килә. Мин дингә килдем дип әйтү бик үк дөрес булмас. Чөнки ана карынында 4 айдан соң адәм баласына җан өрелә, шунда тәкъдире язылып куела. Безнең нинди юлларда йөрүебезне, нәрсәләр эшләгәнебезне, Аллаһы Тәгалә алдан белеп тора, Ул - белүче, күрүче. Боларның барысын да белү, аңлау бик җиңел түгел. Шуңа күрә мәдрәсәләргә килегез, остазлардан белем алыгыз. Без һәрвакыт Аллаһының күзәтеп һәр эшебезне күреп, белеп торуын онытмаска тиешбез. Гомеребезнең иң авыр, иң кыен вакытында, берәү дә безгә ярдәм итә алмый дип уйлаганда без Аллаһының ярдәменә ышанырга тиеш. Барыбыз да Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яши алсак иде. Кешеләрне җәннәткә илтә торган гыйбадәтне генә үтәп яшәргә язсын.

**МӨНИРӘ НӘБИУЛЛИНА, 4НЧЕ КУРС ШӘКЕРТЕ.**

## 2014 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр (1435–1436 һиҗри еллар)

**12/13 гыйнвар- ҺИҖРӘТ КИЧӘСЕ көне.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә (Мөнәвәрә) шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана. **МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ.** Иң зур бәйрәмнәрнең берсе - Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә.

**1/2 май - Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич - Рәгаиб кичәсе** дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**21 май - ИДЕЛ БОЛГАРСТАНЫНДА ИСЛАМ ДИНЕН РӘСМИ РӘВЕШТӘ КАБУЛ ИТКӘН КӨН**

**25/26 июнь - МИГЪРАҖ КИЧӘСЕ.** Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә - Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте.

**12/13 июнь - БӘРАӘТ КИЧӘСЕ,** ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**28 июнь** - изге **РАМАЗАН АЕ** һәм **УРАЗА** башланган көн.

**28 июль - УРАЗА БӘЙРӘМЕ.**

**3 октябрь -** Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфәт тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**4 октябрь - КОРБАН БӘЙРӘМЕ.** Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**25 октябрь** - Хиҗри буенча яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**3 ноябрь - ГАШУРА БӘЙРӘМЕ.** Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота дип хәбәр итте Татарстан Диния нәзарәте матбугат хезмәте.

Район вакыйгасы

## МӘҮЛИД КОТЛЫ БУЛСЫН!

**Рабигүл әүвәл аеның 11нче кичен 12нче көненә бәйләгән баш көнне төн уртасыннан соң Мәүлидин-Нәби, ягъни Мөхәммәд Пәйгамбәрнең туган көнен бөтен мөселманнар зур шатлык белән искә ала.** Рәсүлебез, фани дөньяда 63 ел яшәп, нәкъ шул айның шул көнендә вафат та булган. Әлеге көн уңаеннан чаралар районыбыз авылларында оешкан төстә билгеләп үтелде. Шәһәребездәге Рузалия Ибраһимова җитәкчелегендәге “Ак калфак“ мөслимәләр оешмасы мәдрәсәдә зур бәйрәм ясады: утыздан артык ак яулыклы хатын-кыз бергәләп намаз укыдылар, Пәйгамбәребез рухына багышлап дога кылдылар, мәҗлес табыны артында салаватлар, мөнәҗәтләр әйттеләр. 23нче гыйнварда 10.00 сәгатьтә район мәдәният йортында Мәүлид бәйрәме үтәчәк.

# Намаз – рухи тәрбия чыганагы

**И Раббыбыз,**
**газиз Аллаһ,**
**Рәхмәтеңдә булсак иде,**
**Биш вакыт намазыбызны**
**Вакытында кылсак иде!**

Намаз ул - безне яки аны үтәгән һәр кешене камил шәхес итә торган иң үтемле тәрбия юлларының берсе. Әйе, система тәртибенә кергән биш вакыт намаз җаныбызның төп азыгы буларак аны һәр мизгелдә куәтле. Ягъни намаз белән тукланган көчле җан иясе генә тормышыбызның "яман" (әчкечелек, әхлаксызлык, җинаятьчелек һ.б.) чирләрен җиңәргә сәләтле икәнен тормыш үзе күптән исбатлады. Хәзерге заман педагогика һәм этика фәннәре дә моны кире кага алмый. Намаз ислам нигезләренең берсе буларак бездә нинди сыйфатлар тәрбияли? Гыйльме рух (психология) нигезендәге педагогиканың өйрәтүе буенча кешене 2000 нән артык сыйфат (тырыш, юмарт, үткен, кыю һ.б.) бәяли икән. Ә безнең максат менә шуларның намаз белән тыгыз (үрелгән) бәйләнгәннәрен азмы-күпме ачыклау. Мөселманның төп сыйфатларының берсе-тәкъвалык. Аллаһ Раббыбыз Коръән Кәримнең "Гыймран" сүрәсенең 16-17 нче аятендә: "Сабыр-чыдам булганнар, иманнарына тугры калганнар, итагатьле булганнар, ятимнәрне караганнар (ягъни тәкъвалыкка ирешкәннәр): - Йә Раббыбыз, без иман китердек. Инде безнең гөнаһларыбызны кичер вә безне җәһәннәм газапларыннан коткар!- дип сәхәрләрдә Аллаһтан ярлыкау сорарлар. Тәкъвалык сүзенең телдәге мәгънәсе – нинди дә булса зыянлы нәрсәләрдән саклануны аңлата. Ә шәригатьтәге мәгънәсе - кешенең үзенең Хак Сөбханәһү вә Тәгаләнең ачуыннан һәм газабыннан саклануы: кушканнарын үтәү (шуларның берсе биш вакыт намазны уку); тыйганнарыннан тыелу; газабыннан курку һәм рәхмәтләренә ирешү. Пәйгамбәрләрнең мөһере



**"Намаз".**
**Гөлүсә Габделкаюмова рәсеме**

(с.г.в.) сәхабәсе Гали ибн Әбү Талиб бик үткен әйткән: " Тәкъвалык ул - Аллаһтан курку, Коръән буенча яшәү, әз булган әйбергә риза булу һәм бу дөньядан китү мизгеленә әзер булу." Ә биш вакыт намаз динебезнең терәге буларак тәкъвалык сыйфатын (ислам дине өйрәтүе буенча тәкъвалык алты дәрәҗәдән тора) бик яхшы үстерә. Гыйльме рух фәне өйрәтүе буенча үзара " индукция " кагыйдәсе буенча намаз һәм тәкъвалык бер-берсен "үткенләү" нигезендә безне чын мәгънәсендә тәкъва булырга тәрбияли. Түгәрәкләп, Аллаһның соңгы илчесе (с.г.в.) бер хәдисендә әйтә: "Кайда гына булсаң да, Аллаһтан курык! Гөнаһ артыннан ук, аны юкка чыгару өчен, игелек кыл. Кешеләр белән мөгамәләңдә күркәм әхлактан аерылма! " Бик тирәнгә кермичә генә бу хәдис намазда һәм намаздан тыш тәкъвалык сыйфатын үстерү һәм саклау юлларын бик яхшы аңлата. Икенче төрле әйткәндә һәрдаим биш вакыт намаз белән пакъләнгән җаныбызны "имгәтә" торган күренешләрдән һәм гамәлләрдән саклау тиешлеген ...

Тәкъвалыкны үстерү юлында тугрылык зур әһәмияткә ия. Тугрылыкны Аллаһы Тәгалә безгә фарыз кылган. "Тәүбә" сүрәсенең 119 аятендә Бөек Аллаһ әйтә: " Ий, мөэминнәр! Аллаһ хөкемнәренә хилаф булудан сакланыгыз! Һәм сакланучы тугрылар белән бергә булыгыз!" Тугрылык – ул сөйләгән сүзләрдә һәм һәр гамәлдә хак булу дигәнне аңлата. Намазның тугрылык сыйфатын тәрбияләү мизгелләренең берсе без көн дә 32 тапкыр (фарыз намазларында-17, сөннәт намазларында -12 һәм витр намазында 3 тапкыр ) укый торган " Фатиха " сүрәсенең соңгы аятьләре: Безне туры юлга күндер. Ингам кылып, әүвәлгеләрне күндергән юлыңа күндер, Сине ачуландырган һәм адашкан кешеләр юлыннан башка юлга күндер. Әәәмиин! "

Менә бу 14 гасыр элек кешеләргә Аллаһ Рәсүле (с.г.в.) тарафыннан җиткерелгән "Фатиха" сүрәсенең аятьләре бүгенге галимнәрнең (Дэмис Горбор–Нобелев премиясе авторы, Лондон университеты физигы Дэвид Гэом–Эйнштейн укучысы һәм бүгенге көндә квант физикасының күренекле белгече, нейрофизиология галиме Карл Прайбром, Роберт Дж. Джан – Пристон университеты галиме һ.б.) өйрәтүе буенча көн дә ихлас күңелдән бирелеп Аллаһы Тәгаләдән сорасак, Ул безне һәр сүздә һәм гамәлдә туры юлга күндерә икән. Гыйбадәт кылып Аллаһы Тәгаләдән чын күңелдән һәм ихласлылык белән сораган теләкләр, уйлар, планнар һәм фикерләр тормышка ашарга мөмкин. Ничек дисезме? Җаныбыз юнәлеш биреп торучы безнең акыл бик нечкә һәм хәрәкәттәге энергия (галимнәрнең өйрәтүе буенча) буларак Раббыбызның рәхмәте белән әйләнә, безнең көн дә намазда сораган теләкләргә, ягъни туры юлдан гына йөрергә... Әйе, истикамәтле кеше булу, ягъни Аллаһы Тәгалә боерган рәвештә генә һәр гамәлне, һәр сүзне һәм һәр эшне тугрылык белән генә башкару бик җиңел эш түгел... Инде, иман китергәнбез икән, һәр гамәлдә һәм һәр сүздә истикамәттә булу безнең тугрылык дәрәҗәсен (Гакыйдә фәнендә әлегә тугрылык дәрәҗәләргә бүленмәгән) күрсәтә.

Аны намаздан тыш тәрбияләүгә аз гына тукталып китәбез. Һәркемгә билгеле – дөреслектә (хаклыкны гына алга сөрү) генә безнең Ислам динебезнең ныклыгы. Дөреслек (ялганлый белмәү) һәм гаделлек юлыннан гына баручы мөселман тугрылыктан тайпыла алмый дип өйрәтә гыйльме рух галимнәре. Инде, һәр көнне ястү намазыннан соң дөреслек һәм гаделлек буенча үзебездән имтихан алсак, тугрылык юлына тизрәк басарбыз Аллаһы боерса. Инде, гөнаһ кылган булсак, тәүбә намазын укыйбыз. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тугрылык юлында гаҗәеп искитмәле булуы тормышыннан күренә. Менә аның төп сәбәпләре:

Бер Аллаһы Раббыбызга иман китерү һәм Аңа гына ихлас күңелдән җаны һәм тәне белән гыйбадәт кылу;

Җан, акыл һәм тән бөтен мәгънәсе белән иман нурына кергәч, ягъни нык иманлы мөселман өчен тормышның барлык авырлыклары һәм киртәләре, уенчыкка әйләнә. Чөнки, ул белә шуны ки, бу авырлыкларны иман белән чагыштырып булмаганын, ягъни иман каршында аларның көчсез икәнен; Иман китерү һәм аңа буйсынудан ләззәт тоя белү һ.б.

Киләсе язмаларда, Аллаһы боерса, сабырлык, ихласлылык, һәм ихтыяр көче сыйфатларына тукталып китәрбез.

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ, мәдрәсә шәкерте, гер спорты буенча Гиннесс китабы рекордсмены.**

## Беләсезме?

Җәннәт әһелләренең күбесе–фәкыйрьләр, җәһәннәм әһелләренең күбесе-хатыннар.

**Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: “Җәннәттә мин күпчелек әһелләрнең фәкыйрьләр икәнлеген, җәһәннәмдә күбесе хатыннар булуын күрдем” (Фәтх-аль – Бари 6/318)**

Кешенең вафатыннан соң аңа иртә-кич үзенең керәчәк урынын күрсәтеп торачаклар.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: **“Кеше үлгәннән соң аңа иртә-кич кыямәт көненнән соң булган урынын күрсәтеп торачаклар. Әгәр дә ул җәннәт әһеле икән, аңа җәннәт күрсәтелеп торачак, әгәр җәһәннәм әһеле икән, аңа җәһәннәм күрсәтелеп торачак. Һәм әйтеләчәк: менә сезнең соңгы урыныгыз, - дип. (сахих Мөслим шәрхе 17/300)**

Җәннәт ишекләренең борыслары арасы Мәккә белән Басра шәһәре арасы кебек.

Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: **“Аллаһ белән ант итәм ки, җәннәт ишекләренең борыслары арасы Мәккә белән Басра шәһәре арасы кебектер”. (аль-Бидәя вә-н-ниһәя 2/221)**

Мөхәммәд галәйһиссәләм бармагында көмеш балдак йөртә иде. Ул балдакта аерым өч юл белән “Мөхәммәд - Аллаһының илчесе”,-дип язылган иде.

Әнәс бин Мәликтән риваять ителә ки, Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: “Көннәрдән беркөнне Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенә көмеш балдак ясады һәм балдакка “Мөхәммәд - Аллаһының илчесе”,- дип язып куйды. Шуннан соң ул әйтте: “Мин балдагыма “Мөхәммәд - Аллаһының илчесе”,- дип яздым. Бүтән башка берәү дә бу сүзләрне балдагына язмасын”, -диде.

# Таян Аллага!

*Хаҗиева Әлфирә Шәмсемөхәммәт кызы шигырьләре*

## Хәмер – шайтан азыгы


Җирдә яшәлгән
һәрбер көнебез –
Барчабызга Аллаһ
бүләге.
Чәркә күтәреп матур
сүзләр әйтү –
Адәмнәргә шайтан
теләге.
Тост әйтелде -
әйдә күтәрдек!
(Иблис кушканны
бик тиз үтәдек.)
Фәрештәләр кача,
кыза тантана,
Аллаһ хозурына
бармый теләкләр,
Шайтан “җиңдем”
диеп мактана.
Хәмерсез булмый,
әле туктау юк! –
Шайтан тора
һәрчак котыртып.
Менә шулай җиңел
була диеп,
Кайчак “бау” да
куя тоттырып.
Аллаһ каршы булган
гамәл белән
Теләкләр, һай,
чынга
ашармы?
Хәмерсез булмый –нигә
ният шундый,
Гөнаһ кылмыйча
яшәү начармы?
Арынырга ашыгыйк
шайтан
тозагыннан,
Иманны ныгытып
котылыйк йозагыннан.
“Бисмилла” әйтеп
башлыйк теләкләрне,
Фәрештәләр торсын
“Амин” дип.

## Таян Аллаһка

Мин бәхетле, һәрбер
таңда
Уянам да
әйтәм: “Бисмилләһ”.
Сыенамын
һәрчак, рәхмәтлемен
Гомер биргән өчен
бер Аллаһ.
Яшәү өчен
үзенең колларына
Яралткан камил
Җир шарын.
Күңел күзе күрә
белгәннәргә
Искәртә Ул хак
хуҗа барын.
Күбебезгә тулы
акыл биргән,
Аерыр өчен
ак һәм караны.
Кушканнарын үтик,
югалмасын иман,
Төзек тотыйк
һәрчак араны.
Таяныйк без бары
бер Аллаһка,
Ырым-шырымнарга
ышанмыйк.
Аллаһ бар иткән
мәхлукатка –
Башка бер затка
табынудан сакланыйк.
Аңа гына сыенып була
авыр чакта,
Ярдәм итә
ала бер Аллаһ.
Бирүче дә, алучы да
Аллаһ,
Дөрес яшик,
кылмыйча гөнаһ.
Сатып алып булмый
алтын-көмешкә
Тынычлыкны,
өмет, бәхетне.
Зур ышану белән
таяныйк Аллаһка –
Рәхмәте зур, бирер
якты көнне.
Һәрвакытта – кайгы,
шатлыкта да
Таяна алабыз
бары Аллаһка.
Иман китереп
изгелекләр кылсак,
Әзер булыр урын
оҗмахта!

## Бәрәкәт, бәхет юлы

Җаныбыз иңгән
Аллаһ хозурыннан.
Яралган ул Аның нурыннан.
Раббыбызга иман китергән,
Әмерләрен
үтәргә сүз биргән.
Аллаһ тели
үзенең колларына
Мәңгелек
тормыштагы бәхетне.
Адашмыйча җирдә
яшәү өчен
Маяк итеп биргән Коръәнне.
Ислам дине –бәрәкәт,
бәхет юлы-
Хак юлыбыз, иман
байлыгы.
Намаз белән
рухыбыз чистарына,
Аллаһыга таба юл салына.
Җир өстендә кала
бар байлыклар,
Сыймый алар
бик тар ләхеткә.
Бары Аллаһ
кушканнарны үтәп,
Ирешә алырбыз
зур бәхеткә.
Коръән кушканча яшәү
авыр түгел,
Үз - үзебезне ихлас яратсак.
Ни аяныч булыр
барыр юллар,
Инде күңелләрне караләтсак.
Якты кояш, һава,
әчәр сулар –
Бар нигъмәтне дә
Аллаһ биргән.
Сәҗдә итеп ныграк
якынайыйк -
Изге гамәл белән
ныгый иман.
Кунак булып кына
килдек бары,
Дөньялыкка сынау үтәргә.
Барчабызга насыйп
итсә иде,
Иман белән гомер итәргә.
Дөньялыкта
изгелекләр кылыйк.
Ахирәт
байлыклары булырлык.
Фәрештәләр каршы алып,
Хур кызлары
хезмәт итәрлек.



**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 400 данә.**